РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**КАРАР**
**РЕШЕНИЕ**

24 февраль 2016ел № 9-5

**«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрына үзгәрешләр кертү турында»**

“Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының” 2013елның 25 июнендәге 5-ТРЗ номерлы “Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының” 6 нчы статьясы, Татарстан Республикасы Иминлек Советы карары нигезендә һәм мәгариф өлкәсендә җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең җаваплылыгын арттыру максатларында Буа муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының 2013 елның 19 октябрендәге 10-36 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Муниципаль хезмәтнең югары муниципаль вазыйфалары

муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе;
муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары;
муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;
муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - муниципаль районның башка җирле үзидарә органы җитәкчесе;
муниципаль районның башка җирле үзидарә органы җитәкчесе;
муниципаль районның башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары;
муниципаль район башкарма комитетының эшләр идарәчесе.».

2. Башкарма комитетка үз хокукый актларын әлеге карарга туры китерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Буа муниципаль районы Советы рәисе А.К. Айзетуллов